**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IX СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 45**

Мөслим «26» август 2021 ел

**«2020 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслау турында» 2020 елның 13 февралендәге 170 номерлы Мөслим муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставының 37 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «2020 елга Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслау турында» 2020 елның 13 февралендәге 170 номерлы Мөслим муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2020 елга Мөслим муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планыннан (программасыннан) әлеге карарга кушымтада бирелгән объектларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы Башлыгы урынбасары А.М. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе Р.Х. Муллин

Татарстан Республикасы Мөслим
муниципаль районы Советының
2021 елның 26 августындагы
45 номерлы карарына кушымта

Хосусыйлаштыру планыннан төшереп калдырыла торган мөлкәт исемлеге

1. 376 кв.м мәйданлы Симәк балалар бакчасы бинасы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Симәк авыл җирлеге, Симәк авылы;

2. 672 кв.м мәйданлы Тат.Бүләр балалар бакчасы бинасы, адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Тат.Бүләр авылы, Яшьләр урамы, 12 йорт.

3. 479 кв.м мәйданлы Әмәкәй балалар бакчасы бинасы, кадастр номеры 16:29:120101:173:69; адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим районы, Әмәкәй авыл җирлеге, Әмәкәй авылы, И.Фаррахов ур., 35 йорт.